**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10. 2023 № 733

**2024 елга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль- педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

Россия Федерациясенең “ Мәгариф турында” 2012 елның декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы “Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик,социаль -педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф учреждениеләрен һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” карары һәм “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга расларга:

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларында һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;

балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга төзәтмәләр коэффициенты 0,65 күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Финанс бюджет палатасына тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган эшне яңадан карауны.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов

Расланган
Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2023 елның 13 октябрендәге 733 номерлы карары белән

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һә культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларында һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга**

## НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, 1 укучыга елга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | укытуның беренче елы | укытуның икенче елы | Укытуның өченче һәм аннан соңгы еллары |
| Сәнгати-эстетик | авыл җирлеге | 8 251 | 15 280 | 18 336 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 8 150 | 15 093 | 18 111 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 8 555 | 15 842 | 19 011 |
| Туристик-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Социаль- икътисадый | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |